**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**ерхнеуслонского муниципального района**

422570, село Верхний Услон, ул. Чехова д. 18
тел.: (8843-79) 2-12-67, факс: (8843-79) 2-12-67
E-mail: Ispolkom.Verhniy-usl@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Югары Ослан муниципаль районының**
**Башкарма комитет**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

422570, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18 нче йорт
тел.: (8843-79) 2-12-67, факс: (8843-79) 2-12-67
E-mail: Ispolkom.Verhniy-usl@tatar.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

от ____________________　　　　　　　　№_________

Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан аерым иҗтимагый оешмаларга устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны өлешчә каплауга субсидияләр бирү тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан аерым иҗтимагый оешмаларга устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны өлешчә каплауга субсидияләр бирү тәртибе расларга. (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе　　　　　　　Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды:
Александрова В.Н.
5 экз.

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкченең
2015 елның __________ карарына

1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан аерым иҗтимагый оешмаларга устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны өлешчә каплауга субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип аерым ветераннарның иҗтимагый оешмаларга (алга таба - субсидияләр алучылар) Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен, шулай ук аларны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидияләрне кире кайтару тәртибен билгели.

2. Субсидияләр бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетында каралган бюджет чыгымнары классификациясенең тиешле кодлары буенча чираттагы финанс елына ветераннарның иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Югары Ослан муниципаль районы бюджетында бирелә.

3. Субсидияләр устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплау максатларында түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә.

4. Субсидияләр алучылар Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетына субсидияләр алуга заявкалар бирә. Субсидияләр алуга заявкаларда күчерү өчен реквизитлар, соратып алына торган субсидияләрнең гомуми суммасы, аларны алу кирәклеген нигезләп, күрсәтелә. Субсидияләр алуга гаризалар агымдагы елның 1 маена кадәр кабул ителә.

5. Субсидия алуга заявкага түбәндәгеләр өстәлеп бирелә:

- иҗтимагый оешманың гамәлгә кую документларының (уставының (нигезләмәсенең) күчермәсе, дәүләт теркәве турында таныклык;

- салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

- соралган субсидиянең гомуми суммасына фаразлана торган чыгымнар сметасы.

6. Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетына заявка кергәннән соң 30 календарь көн эчендә заявканы район башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе белән раслана торган комиссия тикшерә.

7. Субсидия алучыларны сайлау түбәндәге критерийлар буенча гамәлгә ашырыла:

- юридик зат буларак дәүләт теркәве булу;

- Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан урын һәм эшчәнлек алып бару;

- ветераннар өчен социаль сәясәт өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү.

8. Тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия субсидияләрне бирү турында һәм аларның күләмнәрен субсидия алучы һәр кеше буенча карар кабул итә.

9. Комиссия карары чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда яисә агымдагы финанс елы бюджетына үзгәрешләр керткәндә карала.

Конкрет алучылар һәм субсидияләр күләмнәре Югары Ослан муниципаль районы Советының район бюджеты турындагы карары белән билгеләнә.

10. Субсидияләр Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты һәм

субсидия алучылар арасында төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

Күрсәтелгән килешү субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен, аларны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидияләрне кире кайтару тәртибен билгеләргә тиеш.

11. Субсидияләрне исәпләү Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә субсидия алучыларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына гамәлгә ашырыла.

12. Субсидияләр алучылар киләсе елның 1 маеннан да соңга калмыйча Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетына субсидияне максатчан файдалану турында хисап тапшырырга тиеш.

13. Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты бирелгән субсидияләрнең максатчан кулланылышын тикшереп тора.

14. Субсидия алучы тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән максатлар, шартлар һәм тәртипләр бозылганда, субсидияләрне кире кайтару әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән килешүдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.